РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
Исполнительный комитет
Масягутовского сельского
поселения
Азнакаевского
муниципального района

ул. Дружба, д. 12, Азнакаевский район,
с.Масягутово, 423321,
тел./факс (885592)38-2-16
E-mail: Msg.Azn@tatar.ru

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
Азнакай муниципаль районы
Мәсгут авыл җирлеге
башкарма комитеты

Дружба ур., 12 йорт, Азнакай районы, Мәсгут
авылы, 423321
тел./факс (885592)38-2-16
E-mail: Msg.Azn@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**от «27» февраль 2023 ел** **№ 2**

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Мәсгут авыл җирлеге Советының 22.01.2014 № 23 карары белән расланган Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы « Мәсгут авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында проектны әзерләү хакында (09.12.2016 № 38, 04.09.2017 №55, 02.07.2018 № 93, 08.04.2019 № 120, 18.02.2020 № 153, 10.08.2021 №35-15, 21.06.2022 №65-32, 21.12.2022 №76-40)

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 8, 33 статьялары һәм «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә «Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2022 елныц 29 декабрендәге 612-ФЗ номерлы Федераль законны үтәү өчен һәм «Россия Федерациясендә тимер юл транспорты турында» Федераль законның 16 статьясындагы 2 пунктының икенче абзацының үз көчен югалтуын тану хакында Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Мәсгут авыл җирлеге башкарма комитеты карар итә:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Мәсгут авыл җирлеге Советының 22.01.2014 № 23 карары белән расланган Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы « Мәсгут авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында проектны (09.12.2016 № 38, 04.09.2017 №55, 02.07.2018 № 93, 08.04.2019 № 120, 18.02.2020 № 153, 10.08.2021 №35-15, 21.06.2022 №65-32, 21.12.2022 №76-40) әзерләүгә керешергә:

1.1. 2023 елның 1 мартыннан Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексына кергән үзгәрешләр белән 4, 16.5, 27, 29, 30 статьяларын туры китерергә.

2. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының « Мәсгут авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында проектны әзерләү эшләрен башкару тәртибен һәм срокларын билгеләргә (1 нче кушымта).

3. Әлеге карарны веб-адрес буенча «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталы»нда урнаштыру юлы белән игълан итәргә: http://pravo.tatarstan.ru һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында: http//aznakayevo.tatar.ru./.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үземдә калдырам.

Башлык Д.З.Миннеханов

Татарстан Республикасы
Азнакай муниципаль районы Мәсгут авыл
җирлеге башкарма комитетының карарына
1 нче кушымта
27 февраль 2023ел №2

**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Мәсгут авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында проектны әзерләүнең якынча сроклары**

| N | «Мәсгут авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында проектны әзерләү эшләрен уздыру тәртибе | Эшләр уздыру срогы |
|---|---|---|
| 1. | Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында проектны әзерләү эшләрен оештыру. | 2023 елның I кварталы |
| 2.<br>2.1. | Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында проектны әзерләү һәм килештерү.<br>Җир белән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренең 4, 16.5, 27, 29, 30 статьяларына үзгәрешләр кертү Федераль законның 29.12.2022 №612-ФЗ нигезендә, җирләрдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проектын килештерүдә катнашучы хезмәтләрнең һәм ведомстволарның искәрмәләренә комментарийлар әзерләү. | 2023 елның I кварталы |
| 3.<br>3.1. | Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында фикер алышу.<br>Гавами тыңлаулар үткәрү.<br>Азнакай муниципаль районының «Мәсгут авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге төзелешенең җирдән файдалану кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында һәм мәҗбүри кушымталар (гавами тыңлаулар беркетмәсе) һәм җир куллану кагыйдәләре проектының юнәлеше турында карар кабул итү өчен гавами тыңлауларның нәтиҗәләре хакында йомгаклау авыл җирлеге Советына раслау яисә кире кагу турында һәм аны, кабат тәкъдим итү датасын күрсәтеп, эшләп бетерергә юнәлдерү урында Азнакай муниципаль районы Мәсгут авыл җирлеге башлыгына юллама. | 2023 елның I - II кварталлары |